ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.07.2025__ Баулы шәһәре №2208______

Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре"
муниципаль берәмлеге территориясендә
терекөмешле лампалар туплану урыннарын
булдыру һәм кулланучыларга мондый
урыннарның урнашуы турында хәбәр итү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законнары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урынын (урыннарын) билгеләргә: Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 йорт.

2. Баулы шәһәре территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыннарының урнашуы турында терекөмешле лампа кулланучыларга

мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә күрсәтелгән урыннар исемлеген урнаштыру, мондый урыннарның әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Соколов